Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Кодаш авыл җирлегенең Биектау торак пунктында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 елның14 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирлеүзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидар әтурында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлегенең Биектау авылында гражданнар җыены **карар бирде**:

1. Кодаш авыл җирлеге Биектау авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 2020 елда 500 сум күләмендә үзарасалым акчасын кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- спорт площадкасы өчен инвентар алу һәм урнаштыру
-Биектау зиратын койма белән әйләндереп алу.
-Биектау авылына гадәттән тыш хәлләрдә халыкка хәбәр итү өчен тавыш сигнализациясе сатып алу һәм урнаштыру.
-Биектау авылына су башнясына насос алу.
-янгын сүндерү машинасы шоферына хезмэт килешүе буенча түләү,машинага ягулык, запас частьлар алу.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Кодаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру,http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы Ф.М. ШАКИРОВ